# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге составынакерүче Шәдче торак пунктында 2025 елга үзарасалым кертү турында

№ 11 30 октябрь 2024 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Шәдче торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Шәдче торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 төркем инвалидлар, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операцияда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары ( хатыны һәм 18 яшькә кадәр булган балалары), көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту: Шәдче торак пунктында Габдулла Тукай урамы юлларын вак таш белән каплау (вак таш, ком сатып алу, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);Шәдче торак пунктында юлларны тигезләү һәм кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);

-беренчел янгын куркынычсызлыгы чаралары белән тәэмин итү: Шәдче торак пунктында янгын сүндерү савытлары сатып алу; Шәдче торак пунктында янгын сүндерү машинасына запас частьлар сатып алу һәм ремонтлау;

-Шәдче торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү(агымдагы ремонт, урамнарны яктырту лампаларын сатып алу һәм алыштыру)).

3.Әлеге карарны Шәдче авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнаржыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.В.Шрыков